СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 гыйнвар 2018 ел г.Мензелинск № 1

**Татарстан Республикасы “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы “Минзәлә муниципаль районы” Уставы нигезендә, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон, 2017 елның 30 октябрендә кабул ителгән №299-ФЗ, 2014 елның 28 июнендә кабул ителгән №172-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 36 нчы маддәсенә үзгәрешләр кертү турында”гы 2017 елның 5 декабрендә кабул ителгән №380-ФЗ “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру” һәм Россия Федерациясенең административ хөкем чыгару Кодексы, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә:

1.1 “Җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләр”нең 6 нчы маддәсе, 1 нче өлешен 33,34,35,36,37 пунктлары белән тулыландырып, аларны түбәндәге редакцияләрдә бәян итәргә:

33) “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проектын төзү һәм карау, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау,

34) муниципаль район чикләрендә, торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, муниципаль район чикләрендә, торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының сакланышын муниципаль контрольдә тоту һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шулай ук

автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә башка вәкаләтләрне тормышка ашыру һәм Россия Федерациясе кануннары нигезендә юл эшчәнлеген башкару,

35) Район территориясендә каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән, аларны аерым җыю), эшкәртү, утильләштерү, зарасызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу,

36) җирлекләрдә авыл хуҗалыгы житештерүчәнлеген үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру, кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә булышлык итү, социаль ориентлашкан коммерциягә бәйле булмаган оешмаларга, хәйриячелек эшчәнлегенә һәм ирекле булышчыларга (волонтерларга) ярдәм күрсәтү,

37) адресланырга тиешле объектларга адрес билгеләү, адресларны үзгәртү, аннулировать итү, урам-юл челтәрендәге (Федераль әһәмияткә ия булган, региональ һәм муниципаль берәмлекләр арасындагы автомобиль юллары керми) элементларга атамалар бирү, шушы атамаларны үзгәртү, аннулировать итү, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру”.

1.2. “Ачык тыңлаулар” 17 маддәсе исемен түбәндәге редакциядә билгеләргә:

«17 маддә. Ачык тыңлаулар, җәмәгать тикшерүләре».

1.3.”Ачык тыңлаулар” 17 маддә, 1 нче өлешен түбәндәге редакциядә кабул итәргә:

«1. Җирлектә яшәүчеләр катнашында җирлек өчен әһәмиятле булган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектларын тикшерү өчен Җирлек Советы, Җирлек башлыгы тарафыннан ачык тыңлаулар, җәмәгать тикшерүләре уздырылырга мөмкин”.

1.4 “Ачык тыңлаулар” 17 маддәсен түбәндәге эчтәлектәге 11 нче пункт белән тулыландырырга кирәк:

«11. Генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территориягә планировка ясау проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төр буенча җир участогыннан яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирелү турындагы карар проектлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җирдән файдалану һәм төзү буенча расланган кагыйдәләр булмаган очракта, җир участогыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану өчен рөхсәт ителгән бер төрдән икенче төргә үзгәртү мәсьәләләре буенча җәмәгать тикшерүләре һәм ачык тыңлаулар уздырыла, аларны оештыру һәм уздыру тәртибе муниципаль берәмлек Уставы һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннардагы положениеләрне истә тотып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә”.

“Ачык тыңлаулар” 17 маддә, 3 нче өлешен түбәндәге редакциядә аңлатып, 5 нче пункт белән тулыландырырга:

“5) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының икътисадый үсеш стратегиясе проекты”.

1.6 “Район Советы компетенциясе” 31 маддә, 1 нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, 25.1 һәм 26.1 пунктлары белән тулыландырырга:

«25.1) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының социаль-икътисадый стратегиясен раслау.

26.1) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау”.

1.7“Башкарма комитет вәкаләтләре” 45 маддә, 1 нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, 8.1 пункты белән тулыландырырга:

«8.1) 2014 елның 28 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында”гы №172-Федераль Законында каралганча, стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләр башкара”.

1.8 “Башкарма комитет вәкаләтләре” 45 маддә, 1 нче өлеш, 1 пунктындагы “Районның социаль сферасын һәм икътисад торышын күрсәтә торган статистик күрсәткечләрне җыюны, кануннарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруны оештыра” абзацын түбәндәге редакциядә күрсәтергә:

“-муниципаль берәмлекнең социаль сферасын һәм икътисад торышын күрсәтә торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыру, һәм әлеге мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыру;”

1.9. “Район башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату” 41 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итеп, 5 һәм 6 нчы пунктлар белән тулыландырырга:

“5. Әгәр Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи затының (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) хокукый акты яисә муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы карары нигезендә, вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылып, муниципаль берәмлек башлыгы әлеге хокукый актка яисә карарга карата суд тәртибендә шикаять белдергән очракта, муниципаль сайлауларда сайлана торган муниципаль берәмлек башлыгын вакытыннан алда сайлау суд карары законлы көченә кермичә торып, билгеләнә алмый.

6. Әгәр Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи затының (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) хокукый акты яисә муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы карары нигезендә, вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылып, муниципаль берәмлек башлыгы әлеге хокукый актка яисә карарга карата суд тәртибендә шикаять белдергән очракта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы суд карары законлы көченә кермичә, конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан сайлана торган

муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турындагы карарны кабул итәргә хокуклы түгел”.

1.10 “Җирлек Уставының, гамәлдәге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карарның үз көченә керү тәртибе” 87 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итеп, 5 нче пункт белән тулыландырырга:

«5. Җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү максатларында уставка кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне чикләү (уставны кануннар белән тәңгәлләштерү, вәкаләтләрне үзгәртү, вәкаләтләр срогы, җирле үзидарәнең вазифаи затларын сайлап алу тәртибе очракларыннан тыш), уставка үзгәрешләр кертү турындагы муниципаль актны кабул итүченең вәкаләтләре срогы чыкканнан соң, ә муниципаль районнарда – муниципаль район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарны имзалаган муниципаль район башлыгы вәкаләтләре чыкканнан соң үз көченә керә”.

1.11 “Халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруы һәм җирле үзидарәне тормышка ашыруда халыкның катнашу формалары” 12 маддәсендәге “ачык тыңлаулар” абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ачык тыңлаулар, җәмәгать тикшерүләре».

1 Гамәлдәге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район башлыгы А.Ф. Салахов.